СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши,
422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Морквашы авылы,
422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

# РЕШЕНИЕ КАРАР

28.11.2024 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. с. Набережные Моркваши 54-311

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр Буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә туристлык салымын кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлегенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә 2025 елның 1 гыйнварыннан туристлык салымын кертергә.

2. Туристлык салымы ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:
- 2025 елда салым базасының 1 проценты күләмендә,
- 2026 елда салым базасының 2 проценты күләмендә,
- 2027 елда салым базасының 3 проценты күләмендә,
- 2028 елда салым базасының 4 проценты күләмендә,
- 2029 елдан башлап салым базасының 5 проценты күләмендә.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов